Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советының сигезенче утырышы

Колай авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

2018 елның 20 сентябре

№ 23

## Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы “Җирле референдум турында” законының 12, 17 статьялары, Колай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. Колай авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә: “2019 елда яшәү урыны Колай авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, 18 яшькә җиткән һәр Россия Федерациясе гражданыннан 500 сум үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны киләсе эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме:

- Колай авылында зиратка юл ремонтлау;
- Карповка бистәсендә Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнарга яңа һәйкәл төзү һәм искесен демонтажлау;
- Тагашево авылы территориясен төзекләндерү;
- Арышхазда авылы Садовая урамы буенча юлны ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Колай авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК”.

2. Әлеге карарны Колай авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Питрәч муниципаль районынын рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Колай авыл җирлеге башлыгы Поповская Н.В. Поповская

СОВЕТ КУЛАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПИТРӘЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1633000850 КПП 163301001 ОГРН 1021607353041 ТАТАРСТАН